# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1 31.10.2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Үчәлле авыл
җирлеге Якты- Күл авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башлыгының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Якты- Күл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"17.10.2025 ел, № 4 карары нигезендә 2025 елның 31 октябрендә узган Якты- Күл авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре белән Якты- Күл авылы гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Якты- Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту)

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Якты-Күл урамыннан зиратка кадәр юлны ремонтлау)

ӘЙЕ КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 49 катнашучы кертелде, җыенында катнашучыларның 34е тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенның 34 катнашучы тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен гражданнар җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1.Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлегенең Якты- Күл авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча караны кабул ителгән дип танырга:

«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Якты- Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту)

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Якты-Күл урамыннан зиратка кадәр юлны ремонтлау).

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 йорт; Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Якты- Күл авылы, Якты- Күл урамы, 15 нче йорт адреслары буенча Үчәлле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http://aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштырып халыкка чыгарырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге башлыгы Г.М. Төхвәтуллина